КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 14 июнь г.Казань № 482

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карар белән расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2012 ел, 1 август, 653 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 27 ноябрь, 1036 нчы; 2013 ел, 30 гыйнвар, 52 нче; 2013 ел, 29 июнь, 458 нче; 2014 ел, 24 гыйнвар, 36 нчы; 2014 ел, 15 февраль, 91 нче; 2014 ел, 27 июнь, 443 нче; 2014 ел, 29 июль, 553 нче; 2014 ел, 2 август, 565 нче; 2014 ел, 10 октябрь, 752 нче; 2014 ел, 22 октябрь, 775 нче; 2015 ел, 2 апрель, 209 нчы; 2015 ел, 22 июль, 536 нчы; 2015 ел, 3 ноябрь, 833 нче; 2016 ел, 26 май, 356 нчы; 2016 ел, 30 июнь, 449 нчы; 2017 ел, 16 март, 144 нче; 2017 ел, 20 июнь, 400 нче; 2017 ел, 5 сентябрь, 636 нчы; 2017 ел, 26 октябрь, 809 нчы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләре хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

7 бүлектә:

7.2.7 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.2.7. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре сәламәтлек саклау һәм социаль хезмәтләр күрсәтү өлкәсендә мәшгуль хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнгән чор (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук нәтиҗәле хезмәткә ирешүне стимуллаштыру максатларында, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы халкына социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең нәтиҗәлелеген һәм сыйфатын күтәрү (2013 – 2018 еллар)» чаралар планын («юл картасын») раслау турында» 2013 ел, 29 май, 359 нчы карары белән расланган Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән социаль өлкә тармакларындагы үзгәрешләр (2013 – 2018 еллар)» чаралар планын («юл картасын») үтәгәндә һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 597 нче Указын тормышка ашырганда Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм социаль яклауның дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, бер тапкыр, вакытның билгеле бер чоры (ай, квартал, ел) өчен, юбилей даталары, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча билгеләнә.»;

7.3.6 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.3.6. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре мәгариф хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вакытның билгеле бер чоры (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук гә юбилей даталары, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.»;

7.4.5 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.4.5. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре фәнни тикшеренүләр һәм эшләнмәләр өлкәсе хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вакытның билгеле бер чоры (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук гә юбилей даталары, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.»;

7.5.8 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.5.8. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре медицина һәм фармацевтика хезмәткәрләр вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә билгеләнгән чор (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук нәтиҗәле хезмәткә ирешүне стимуллаштыру максатларында, шул исәптән Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 30 март, б-557 нче боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасында сәламәтлек саклау өлкәсенең нәтиҗәлелеген күтәрүгә юнәлдерелгән социаль өлкә тармакларындагы үзгәрешләр»(2013 – 2018 еллар) чаралар планын («юл картасын») үтәгәндә һәм һәм Россия Федерациясе Президентының «Дәүләт социаль сәясәтен тормышка ашыру чаралары турында» 2012 ел, 7 май, 597 нче Указын тормышка ашырганда Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмалары һәм социаль яклауның дәүләт

учреждениеләре хезмәткәрләре эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген күтәрү максатларында, бер тапкыр, вакытның билгеле бер чоры (ай, квартал, ел) өчен, юбилей даталары, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән бүтән нигезләр буенча билгеләнә.»;

7.6.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«7.6.5. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре фәнни мәдәният, сәнгать һәм кинематография хезмәткәрләре вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренә вакытның билгеле бер чоры (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук гә юбилей даталары, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.»;

Татарстан Республикасының халыкка социаль хезмәт күрсәтүче дәүләт оешмаларының һәм дәүләт социаль яклау учреждениеләренең эшчеләр гомумтармак һөнәрләренең һәм җитәкчеләр, белгечләр һәм хезмәткәрләр гомумтармак вазыйфаларының һөнәри квалификация төркемнәренә керә торган хезмәткәрләр хезмәте өчен түләү шартлары турында нигезләмәнең 3.15 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.15. Премиаль һәм башка бүләкләү түләүләре хезмәткәрләргә вакытның билгеле бер чоры (ай, квартал, ел) өчен, шулай ук гә юбилей даталары, аерымлык билгеләрен, рәхмәт хатларын, грамоталар, дәүләт бүләкләрен алу белән бәйле һәм оешманың локаль актлары һәм күмәк шартнамәләре белән билгеләнгән башка нигезләр буенча билгеле бер чор (ай, квартал, ел) өчен бер тапкыр билгеләнә.».

2. Бу карарның гамәле 2018 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин